СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯМБУЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30.09.2016** **с.Ямбулатово** **№ 13 – 59**

Ямбулат авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Ямбулат авыл җирлеге Советының 20,09, 2016 нчы елларда кабул ителгән 12-56 нчы номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Ямбулат авыл җирлеге башлыгының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»2016 ел, 5 нче июнь, 5 нче номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2016 елның 20 ноябренә Ямбулат авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2017 елда Ямбулат авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Ямбулат авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратны төзекләндерү: 2000 метр озынлыктагы койма, керү төркемен 1 данә итеп ясау.

ӘЙЕ ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н. Әхмәтҗанов